Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның 16 июлендәге
189/ИК-п номерлы карарына 13 нче кушымта

# 1. Балигъ булмаганнарның күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 2. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент балигъ булмаган балага караган күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәт алучылар: ундүрт яшькә җиткән Россия Федерациясенең балигъ булмаган гражданнары яки балигъ булмаган яшьтәге күчмә милкен читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт алырга теләүче ундүрт яшькә җитмәгән, балигъ булмаган яшьтәге гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба-мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Буа муниципаль районының Башкарма комитеты (алга таба Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Башкарма комитет каршындагы дәүләт хезмәтен башкаручы - опека һәм попечительлек бүлеге (алга таба - Бүлек)

1.3.1. Опека һәм попечительлек бүлеге урнашкан урын : 422430, Буа ш., Жорес ур., 110А.

Эш графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән кала.

дүшәмбе - җомга 8-00 дән 17-00 гә кадәр, төшке аш 12-00 дән 13-00 гә кадәр.

Үтү шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. Бүлек телефоны: 8 (84374) 3 40 34.

1.3.3. Башкарма комитетның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты адресы (алга таба - «Интернет» челтәре): http://buinsk.tatarstan.ru.,bua@tatar.ru электрон почтасы адресы.

Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

башкарма комитет биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

«Интернет» челтәре аша:

Башкарма комитетның рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

бүлеккә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бүлек белгече тарафыннан башкарма комитетның рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен бүлек бүлмәләрендә урнаштырыла.Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ал

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясенең 1994.30.11, 51-ФЗ№ Граждан кодексы (алга таба – РФ ГК) (РФ законнары җыелмасы, 05.12.1994, 32№, 3301 ст.,«Российская газета», 238-239, 08.12.1994);
- Россия Федерациясенең 29.12.1995, Гаилә кодексы (алга таба – РФ ГК) (РФ законнары җыелмасы, 01.01.1996, 1№, 16 ст.,«Российская газета», 17№, 27.01.1996);
- 2008 елның 24 апрелендәге «Опека һәм попечительлек турында» 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ№ Федераль закон) ( «Российская газета», 94№, 30.04.2008, Ватаным

Татарстан, № 94, "Парламентская газета" 31-32№, 07.05.2008, Россия Федерациясе законнары җыелмасы 28.04.2008, 17№ 1755 ст.);

- 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон; (алга таба - 210-ФЗ№ Федераль закон) («Российская газета», 168№, 30.07.2010, « Россия Федерациясе законнары җыелмасы», 02.08.2010, 31№, 4179 ст.);

- Татарстан Республикасының 13.01. 2009, 4-ТРЗ№ Гаилә кодексы (алга таба – ТР ГК) ("Татарстан Республикасы" 8№,16.01., "Ватаным Татарстан", 8№, 17.01.2009, Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1№, гыйнвар,2009ел );

- 2004 елның 27 февралендәге «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба-8-ТРЗ№ Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2№, февраль, 2004 ел, "Республика Татарстан", 43 -44№, 02.03. 2004, ТР МК карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 21№, 26.05.2004);

- 2008 елның 20 мартындагы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы ("Ватаным Татарстан", 54№, 22.03.2008, "Республика Татарстан" 60-61№, 25.03.2008, Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 3№, март, 2008);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 880 номерлы карары (алга таба – ТР МК 880№ карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, 46№, 2144 ст.; 20.12.2011, 48№, 2612 ст.; 25.05.2012, 40№, 1252 ст.);

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2013 елның 20 декабрендәге 4-37 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында (Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 28 маендагы 1-49 номерлы, 2016 елның 15 июлендәге 9-1 номерлы, 2017 елның 15 сентябрендәге 6-24 номерлы карарлары редакциясендә);

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 17 апрелендәге 3-47 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә белән;

“Буа муниципаль районы советының 2016 елның 24 февралендәге 10-5 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы опека һәм попечительлек бүлеге турында Нигезләмә белән;

- Буа муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 07 апрелендәге 81-р номерлы расланган балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча баш белгечнең вазыйфаи инструкциясе.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

опека - суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру рәвеше, алар вакытында опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) тәрбиядәге балаларның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик әһәмиятле барлык гамәлләрне башкаралар;

опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән граждан (попечитель) үз хокукларын һәм бурычларын үтәүдә ярдәм итәргә, шулай ук аларны өченче зат тарафыннан явызларча файдаланулардан сакларга тиеш булган ундүрт яшьтән унсигез яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны урнаштыру рәвеше:

опека (попечительлек) түләүсез шартларда мөрәҗәгать итүче белән туганлык мөнәсәбәтләрендә торучы балигъ булмаганнарга карата билгеләнә, бу баланы сайлап алу процедурасын кире кага;

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәт күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандарт таләпләре эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәте атамасы | Балигъ булмаган балага караган күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләрне тормышка ашыруга алдан рөхсәт бирү | 48-ФЗ№ Федераль законның 21 ст.;<br>РФ ГК 37 ст.<br>РФ ГК 28 ст.<br>8-ТРЗ№ ТР Законының 5 ст. |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге | 8-ТРЗ№ ТР Законының 5 ст. |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тасвирлау | Балигъ булмаган балага караган күчмә милкен читләштерү буенча килешүләрне тормышка ашыруга боерык (карар) формасында рөхсәт<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән хат рәвешендә баш тарту | 48-ФЗ№ Федераль законның 21 ст.<br>8-ТРЗ№ ТР Законының 5 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | "Опека һәм попечительлек турында" 48 - ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 1 һәм 2 кисәкләрендә каралган Опека һәм попечительлек органының алдан рөхсәт яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту опекунга яисә попечительгә мондый рөхсәт бирү турында гариза бирелгән датадан унбиш көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә бирелергә тиеш. Опека һәм попечительлек органы тарафыннан мондый рөхсәт бирүдән баш тарту дәлилләнгән булырга тиеш. Опека һәм попечительлек органы тарафыннан бирелгән яки мондый рөхсәт бирүдән баш тартуга карата суд тәртибендә опекун яки попечитель, башка кызыксынган затлар, шулай ук прокурор тарафыннан дәгъва белдерелергә мөмкин. | 48-ФЗ№ Федераль законның 21 ст. |
| 2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле | 1. Ата-аналарның (икесенең дә) яисә аларны алмаштыручы затларның алыш-бирешне башкаруны рөхсәт итү турындагы үтенече белән гаризалары | |

| | | |
|---|---|---|
| документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләрнең тулы исемлеге | (мөрәҗәгать итүче),<br>яки<br>законлы вәкилләрнең язма ризалыгы белән эш итүче ундүрт яшькә җиткән балигъ булмаган баланың гаризасы (1 нче кушымта);<br>2. Ата-анасы яисә аларны алмаштыручы затларның паспорт оригиналы һәм күчермәләре;<br>3. Балигъ булмаган баланың туу турында таныклыгы оригиналы һәм күчермәсе (14 яшьтән паспорт) ;<br>4.Җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар;<br>5. Ана капиталы акчаларын җәлеп итеп, торак сатып алган очракта:<br>-ана капиталы сертификатының күчермәсе;<br>- ана капиталын индексацияләү турында белешмә. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан кирәкле документлар:<br>- балигъ булмаганның килешүгә рөхсәт бирелә торган муниципаль районнан булуын раслаучы теркәү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә;<br>- торак мәйданының шәхси финанс счетлары һәм йорт кенәгәсеннән торак урыннарны сатып алу (алмаштыру) урыныннан аерым алынган өземтәләр;<br>- сату урыныннан һәм сатып алу (алмашу) урыныннан аерым күчмә милкен хокук билгели торган документлар (Росреестр, БТИ). | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм ул дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле | 1. Тапшырылган документларның 2.5 пунктында | |

| | | |
|---|---|---|
| документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Бирелгән документларда килешенмәгән төзәтмәләр булу;<br>3. Мөрәҗәгатьнең факттагы яшәү урыны буенча булмавы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Кире кагу өчен нигезләр:<br>1. Законлы вәкилләрнең ризалыгы булмау.<br>2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү хокукы билгеләүче тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документларны, тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләрне тапшыру;<br>3.Балигъ булмаган баланың милеккә хокукларын кысу.<br>Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр юк. | 8-ТРЗ№ ТР Законының 5 ст. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүчене кабул итү (хезмәт күрсәтү) көтү вакытының максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең үтенечен теркәү срогы | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткечләр белән | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү бинасына, көтү залына, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмати стендларга, шул исәптән күрсәтелгән объектларның инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләр | җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү махсус бүлеп бирелгән тәэмин ителгән урыннарда гамәлгә ашырыла:<br>янгын системасы һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;<br>мәгълүмати стендлар.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз үтеп керүе тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм эчендә хәрәкәт) | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу һәм сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:<br>1) мөрәҗәгать итүченең яшәү районында опека һәм попечительлек органы булу;<br>2) мәгълүмат стендлары булу.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын үтәү. | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелә алмый | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы

3.1.1. Балигъ булмаган балага караган күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләрне тормышка ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2)мөрәҗәгать итүчене, документларны кабул итү (әлеге Регламентның 2.5п.);

3) ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) балигъ булмаган балага күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләрне тормышка ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча рөхсәт әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) мөрәҗәгать итүчегә нигезләр булганда дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

Гариза бирүче шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яисә) хат белән дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен опека һәм попечительлек органына мөрәҗәгать итә.

Опека һәм попечительлек органы белгече тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлеге, составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр, кисәтүләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене, документларны кабул итү.

3.3.1.Мөрәҗәгать итүче әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны опека һәм попечительлек органына шәхсән тапшырыла.

3.3.2. Кабул итүне алып баручы опека һәм попечительлек органы белгече гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

документлар булу-булмавын тикшерү;

бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бетерүләр, өстәмәләр, сызылган сүзләр һәм башка килешенмәгән төзәтмәләр булмау).

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза кабул итү датасы һәм аңа кушып бирелә торган документлар турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, гариза биргәндә опека һәм попечительлек органы белгече гаризаны теркәү өчен киртәләр булу турында шәхсән үзе хәбәр итә һәм аңа документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язмасы, алу кәгазе яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Опека һәм попечительлек органы белгече әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын тикшерә.

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече баш тарту турында хат әзерли һәм мөрәҗәгать итүчегә имза куелганнан соң 3 көнлек срокта җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документлар да кире кайтарыла һәм карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла. Әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, белгеч мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлардагы белешмәләрне тикшерү эшен оештыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Ведомствоара мөрәҗәгатьне формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Опека һәм попечительлек органы белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша мөрәҗәгать җибәрә:

- балигъ булмаганның килешүгә рөхсәт бирелә торган муниципаль районнан булуын раслаучы теркәү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә алу;

- торак мәйданының шәхси финанс счетлары һәм йорт кенәгәсеннән торак урыннарны сатып алу (алмаштыру) урыныннан аерым алынган өземтәләр алу;

- сату урыныннан һәм сатып алу (алмашу) урыныннан аерым күчемсез мөлкәткә хокук билгели торган документлар (Росреестр, БТИ).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.3.3 пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлау мизгеленнән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән мөрәҗәгать.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан опека һәм попечительлек органы мөрәҗәгатьләре буенча автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла:

- мөрәҗәгатьне эшкәртү һәм соралган мәгълүматларны эзләү,

- соратып алына торган мәгълүматларның ведомствоара электрон бәйләнешен формалаштыру, яки соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары мөрәҗәгатьләре кергән көннән алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгатькә җавап яки әлеге Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Балигъ булмаган балага күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү турында күрсәтмә (карар) яки баш тарту турында хат әзерләү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек органы белгече тапшырылган документлар нигезендә, балигъ булмаган балага караган күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү турында күрсәтмә (карар) проектын әзерли һәм аны килештерүгә җибәрә ( катлаулы мәсьәләләр булган очракларда, балигъ булмаганнарның хокукларын яклау комиссиясендә карала, бу тәкъдим итү характерына ия) һәм опека һәм попечительлек органы җитәкчесендә раслый яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: балигъ булмаган балага күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт алу турында күрсәтмә (карар) яки 3.7 п.нигезендә әзерләнгән баш тарту турында хат.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек органы белгече, балигъ булмаган балага күчмә милкен алу буенча алыш-бирешне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт алу турында имза куелган күрсәтмә (карар) алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшыра (җибәрә). Тискәре нәтиҗә булган

очракта, хатны шәхсән кулга тапшыра яки 3.7 п. нигезендә почта аша хәбәрнамә белән заказлы хат белән җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, 3.5.1 пунктта каралган процедурадан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек органы белгече, рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли (алга таба – баш тарту турында хат).

Әзерләнгән хат проекты имзага Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының (шәһәр округының) опека органы җитәкчесенә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклаганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла

Процедураларның нәтиҗәсе: имза куюга җибәрелгән баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хат проектына имза куя һәм опека һәм попечительлек органы белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә имза куелган көннән 3 көн эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документлар да кире кайтарыла һәм карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.7 пунктчасында каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү, опека һәм попечительлек органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләре булган җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- эш башкаруны алып бару буенча билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр үткәрү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшерү уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең үтәлешен контрольдә тоту максатыннан опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамау өчен җаваплы.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәрге (судтан тыш) тәртип

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренең судка кадәр гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Буа муниципаль районы Башкарма комитетына яисә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына шикаять белдерү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять кәгазьдә яисә электрон формада язма рәвештә бирелә.

Шикаятьне почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, башкарма комитетның рәсми сайтыннан (http://www.buinsk.tatar.ru), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланырга, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять биргән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр - физик зат йә исеме, мөрәҗәгать итүче - юридик зат урнашкан урын турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номеры), электрон почта адресы (адресы) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәткәрнең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи затының карары һәм гамәл кылмавы (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә аны биргән дәүләт хезмәтен алучы имза сала.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча башкарма комитет җитәкчесе (җитәкче урынбасары) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару формасында, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басмаларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7.1 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

**Балигъ булмаган бала караган** күчмә милкен **читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымта**

**_______________________________________**

**______________________________________**

**гражданнан____________________**

**(Ф.И.О.)**

**_________________________________________,**

**паспорт_________________________________**

**_________________________________________,**

**_______________________________________адресы буенча яшәүче**

**__________________________________ телефон**

## ГАРИЗА

_______________________________________________читләштерүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм
(сатып алу-сату, алыштыру)
____________________________________________________________________________________
(хосусыйлаштырылган, хосусыйлаштырылган, милеккә, кооператив, дәүләт) фатирына, (торак йорт) __________________________________________________________адресы буенча урнашкан
гомуми мәйданы _ _ _ _ _ _ кв. м, торак мәйданы _ _ _ _ кв. м, Бүлмәләр саны______,
**фатир милекчеләре булып тора:**

**____________________________________________________________________________________**

**(Ф.И.О., өлешләрен күрсәтергә)**

**____________________________________________________________________________________________________________________________________________________________**

**____________________________**

**____________________________________________________________________________________**

**____________________________________________________________________________________**

шул исәптән балигъ булмаган балалар (бала) :
____________________________________________________________________________________
(Ф. И. О..- туган көне, өлешен күрсәтергә)
_____________________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________сәбәпле
(торак шартларын яхшырту, күченү һ. б.)
сатып алабыз ________________________________________________________________,
(фатир (җир кишәрлегендә урнашкан торак йорт)
гомуми мәйданы _ _ _ _ _ _ кв. м, торак мәйданы _ _ _ _ кв. м, бүлмәләр саны________
_______________________________________________________________________________________________
_____________________адресы буенча урнашкан
___________________________________________________________________________________
кайда балигъ булмаган балага __________________________________________________
(Ф.И.О.)
бүлеп биреләчәк____________ өлеш.

Өстәмә мәгълүмат (кредит җәлеп итү, сатып алына торган фатирны залогка тапшыру һәм башка йөкләмәләр, ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификатын куллану):

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________.

Балаларның милек һәм торак хокуклары кысылмый.

ТР буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсендә сату-алу килешүен теркәгәннән соң ике атна эчендә опека һәм попечительлек бүлегенә сату-алу шартнамәсенең һәм хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәләрен тапшырырга вәгъдә бирәм.

Минем шәхси мәгълүматлар белән эшкә рөхсәт бирәм.

_____________________ __________________

(дата) (имза)

Мин,_______________________________________________________________________________

(14 яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаган балаларның ФИО)

законлы вәкилләрнең гаризасы белән килешәм.

_____________________ __________________

(дата) (имза

2 нче кушымта
**Кушымта**
**(белешмә)**

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге**

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы | (84374) 3 40 34 | Gulnaz.Halitova@tatar.ru |
| Бүлек белгече | (84374) 3 40 34 | Aygul.Fashutdinova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84374) 3-10-93 | bua@tatar.ru |
| Башкарма комитетның эшләр идарәчесе | 3-12-02 | Milyausha.Yunusova@tatar.ru |

**Балигъ булмаган бала караган** күчмә милкен
**читләштерү буенча килешүне гамәлгә**
**ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт**
**хезмәте күрсәтүнең Административ**
**регламентына 3 нче кушымта**

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**

